МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2026 Казан ш. № 587-пр

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителгән административ регламентын расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының түбәндәге боерыкларын:

«Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 30.09.2022 № 584-пр;

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.09.2022 № 584-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 08.05.2024 № 268-пр;

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.09.2022 № 584-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 23.01.2025 № 26-пр;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 22.05.2023 № 340-пр боерыгы белән расланган “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында” боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрнең 4 пункты;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.06.2025 № 335-пр боерыгы белән расланган “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында” боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрнең 3 пункты;

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
22.05.2026 № 587-пр
боерыгы белән расланган

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртипләрен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте) һәм Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә карый.

Шартлы билгеләр һәм кыскартмалар исемлеге бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

1.2. Дәүләт хезмәте алуга гариза бирүчеләр булып юридик яки физик затлар, шәхси эшмәкәрләр тора.

Гариза бирүче исеменнән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән документлар нигезендә тиешле вәкаләтләр бирелгәнлеген раслаган затлар (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) эш йөртә ала.

Гариза бирүчеләрнең категория идентификаторы (билгеләре) бу Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә гариза бирүченең категорияләренә (билгеләренә) туры китереп күрсәтелә, аның турында белешмәләр “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – хезмәтләр реестры, Бердәм портал) урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү.

2.2. Башкарма хакимият органы атамасы

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы.

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Министрлыкның дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлеге (алга таба - Бүлек).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) җирләрне яки җир кишәрлеген куллану рөхсәте әлеге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән формада;

2) җир кишәрлегендә объект урнаштыру рөхсәте әлеге Регламентка 7 нче кушымтада китерелгән формада;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлегендә объект урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар) әлеге Регламентка 8 нче кушымта китерелгән формада.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мәгълүмат системасында реестр язуы формалаштыру каралмаган.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерүне гариза бирүче үзе сайлаган ысул буенча ала:

гариза бирүченең шәхсән үзенә язмача яки электрон документ формасында;

электрон документ формасында гариза бирүченең Республика порталындагы, “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмати система” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы http://lk.eisestate.tatar.ru (алга таба - ЕИС «Имущество») шәхси кабинетына;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба - МФЦ) Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты, әгәр Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә объектлар

урнаштыруга рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелгән булса, гариза кергән көннән башлап 15 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинет аша бирелгән булса, гаризага эш номенклатурасына туры китереп номер һәм Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетта күренеп торучы «Документларны тикшерү» статусы куелган көннән соң 15 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан МФЦ аша бирелгән булса, дәүләт хезмәте, МФЦ Регламентында каралган срокны да истә тотып, 15 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.4. Министрлыкта һәм МФЦда дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гариза бирүче күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәрү дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Республика порталын, ЕИС «Имущество»ны, Министрлыкның рәсми сайтын кулланган башка түләүләр каралмаган. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты - 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросын регистрацияләү срогы

2.7.1. Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан МФЦ аша бирелгән запрос МФЦдан кергән көнне Министрлык тарафыннан регистрацияләнә.

Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦның Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелүен раслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән регистрация номерлы расписка бирелә.

2.7.2. Гариза Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гариза җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү ала.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

2.7.3. Гариза почта аша юлланса, гариза бирүчегә гариза Министрлыкка кергән көнне электрон почта белән гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү юллана.

2.7.4. Гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, гариза бирелгән көнне министрлык хезмәткәре гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән расписка бирә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр Министрлыкның рәсми сайтына, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.9. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре Министрлыкның рәсми сайтына, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Бүлеккә мөрәҗәгать итсә, гариза бирүчегә консультация бирелә ала.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, гариза бирү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү өлешендә, теләсә кайсы МФЦда, үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда, мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына яки фактта яшәгән (торган) (физик затлар өчен, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп) яисә урнашкан урынына карамастан (юридик затлар өчен) сайлавы буенча экстерриториаль принцип буенча гамәлгә ашырыла.

2.10.4. МФЦда дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге каралган.

2.10.5. Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү каралган.

2.10.6. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында, ЕИС «Имущество»да урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ) туры китереп алдарак расланган документлар һәм мәгълүматны Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән запросның үтәлеше турында белешмә алу;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять итү.

Гаризаны формалаштыру Республика порталында, ЕИС «Имущество»да электрон формада запрос тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гариза бирү зарурлыгы юк.

2.10.7. Гариза формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзалланган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан запросның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән запросларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган гаризаларга да.

2.10.8. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, ЕИС «Имущество», Министрлык телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегә раслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итәргә каршылык тудырмый.

2.10.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомствоара электрон арадашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.11. Әлеге Регламентның пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларын үтәү кысаларында пространство белешмәләренең илкүләм системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан яисә башка технологик һәм программа чараларыннан файдалану рөхсәт ителә.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге

2.11.1. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән: алар мөрәҗәгать итүче үзе мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка, һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документларга бүленә.

2.11.2. Гариза формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен, һәм аларны гариза бирүчегә кайтару өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән

2) әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау.

3) гариза формасында мәҗбүри юлларның дөрес тутырылмавы, шул исәптән, Республика порталында, ЕИС «Имущество»да гаризаның интерактив фоормасында (дөрес булмаган, тулы булмаган, яисә дөрес тутырылмаган).

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.12.3. Түбәндәге шартларның берсенең генә булса да булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

Җир кишәрлеген кулланырга рөхсәт алу өчен:

1) гариза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2014 елның 27 ноябрендәге № 1244 карары (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 1244 карары) белән расланган Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген

кулланугa рөхсәт бирү тәртипләренең 3, 4 пунктлары белән билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән;

2) гаризада җирләрне яки җир кишәрлеген яки урнаштырыласы объектларны куллануның РФ ҖКның $39^{34}$ статьясының 1 пунктында каралмаган максатлары күрсәтелгән;

3) куллану өчен рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге физик яки юридик затка бирелгән.

Объектларны урнаштырырга рөхсәт алу өчен:

1) гариза "Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибе һәм шартларын раслау турында" 2015 елның 5 июнендәге № 416 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – ТР МКның № 416 карары) белән расланган төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру Тәртибе һәм шартларын 8 һәм 9 пунктлары белән билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылган;

2) гаризада күрсәтелгән күздә тотылган объектларның төрләре РФ ҖКның $39^{36}$ статьясының 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган объектлар төрләре исемлегенә керми;

3) Министрлыкка объектлар урнаштыру өчен планлаштырылган җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле милек хокукларын гамәлгә ашыру хокукы бирелмәгән, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләре йөкләнмәгән;

4) планлаштырылган җир кишәрлеге гражданнарга яки юридик затларга бирелгән;

5) планлаштырылган җир кишәрлегендә объектлар урнаштыру аны куллану рөхсәт ителгән төрдә кулланып булмауга китерә;

6) җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{11}$ статьясының 19 пункты нигезендә үткәрелүе хәбәр ителгән аукцион предметы булып тора;

7) җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле РФ ҖКның $39^{18}$ статьясы 1 пунктының 1 подпунктына туры китереп, җир кишәрлеген хосусый торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык белән шөгыльләнү яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге өчен бирү турында белдерү бастырылган;

8) объектлар урнаштыру өчен планлаштырылган урын "Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә генә урнаштырып була торган объектларның төрләре исемлеген раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2014

елның 3 декабрендәге № 1300 карары белән расланган Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә генә урнаштырып була торган объектларның төрләре исемлегенең 25 пунктында күрсәтелгәннәр арасында, урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт соралмаган велосипедлар, роликлар, самокатлар һәм башка спорт инвентаре прокаты пунктлары, шулай ук, ТР МКның № 416 карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибе һәм шартларынның 3 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән велопарковкалар урнаштыру схемасы белән каралмаган.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, әлеге Регламентның 8 нче кушымтасында китерелгән формада.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), административ процедура таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны гамәлгә ашыру, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гамәлгә ашырыла торган чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны), мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын,

бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатланырга рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын күздә тоткан бүленеш каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене профильләү;

2) гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати арадашлык;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын әзерләү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан эшләү (проактив) режимында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның запросы статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат аша;

– Республика порталы аша;

– ЕИС «Имущество» аша;

– башка сервислар һәм ысуллар кулланып (булса).

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) - Реестр);
3. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы – ЕИС «Имущество» (http://lk.eisestate.tatar.ru);
4. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры – Хезмәт күрсәтүләр реестры;
5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы – Министрлык;
6. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – МФЦ.
7. Россия Федерациясе Җир кодексы – РФ ҖК;
8. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2014 елның 27 ноябрендәге № 1244 карары - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 1244 карары;
9. “Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибе һәм шартларын раслау турында” 2015 елның 5 июнендәге № 416 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары – ТР МКның № 416 карары.

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

## Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | җирләрне яки җир кишәрлеген куллануга рөхсәт | физик зат | 1А |
| 2. | | шәхси эшмәкәр | 2А |
| 3. | | юридик зат | 3А |
| 4. | | гариза бирүченең вәкиле | 4А |
| 1. | җир кишәрлегендә объект урнаштыруга рөхсәт | физик зат | 1Б |
| 2. | | шәхси эшмәкәр | 2Б |
| 3. | | юридик зат | 3Б |
| 4. | | гариза бирүченең вәкиле | 4Б |

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

## Исчерпывающий перечень документов, необходимых для предоставления государственной услуги

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группа документлары саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүче үзе тапшырырга тиешле документлар | | | |
| 1. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | кәгазь документ формасындагы гариза | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| | 1А-4А;<br>1Б-4Б | электрон формадагы гариза | Республика порталы, ЕИС «Имущество» (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла) |
| 2. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | Шәхесне раслаучы документ | МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 1А-4А | Шәхесне раслаучы документ күчермәсе | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә, Республика порталы, ЕИС «Имущество» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 5. | 3А-4А;<br>3Б-4Б | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә, Республика порталы, ЕИС «Имущество» |
| 6. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | территориянең кадастр планында файдалану күздә тотыла торган җирләр яисә җир кишәрлегенең бер өлеше чикләре схемасы, территория чикләренең характерлы нокталарының координаталарын күрсәтеп - җирдән яисә җир кишәрлегенең бер өлешеннән файдалану планлаштырылган очракта (күчемсез милек бердәм дәүләт реестрын (алга таба – ЕГРН) алып барганда кулланылган координаталар системасын файдаланып | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 7. | 1Б-4Б | объектларны урнаштыру проектын техник-икътисадый нигезләү яисә кирәкле исәп-хисаплар – мөрәҗәгать итүче теләге буенча тапшырыла | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 8. | 1Б-4Б | планлаштырыла торган җир кишәрлегендә объектларны урнаштыруның кирәклеген раслый торган башка документлар - мөрәҗәгать итүче теләге буенча тапшырыла | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 9. | 1А-4А | җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән Россия Федерациясе Җир кодексының 39[34] статьясындагы 1 пунктында каралган максатларда файдалану нигезләрен раслый торган башка документлар - мөрәҗәгать итүче теләге буенча тапшырыла | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, дәүләт хезмәте күрсәтелү өчен мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документлар | | | |
| 1. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 2. | 3А, 4А;<br>3Б, 4Б | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ) | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 2А, 4А;<br>2Б, 4Б | Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында ТР буенча ФСХИдан | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 4. | 1Б-4Б | Муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының объектлар урнаштыруга ризалыгы (тиешле | Республика порталы, ЕИС «Имущество», |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетыннан). | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 5. | 3А, 4А | Җир астын геологик яктан өйрәнү буенча эшләр башкару хокукын раслаган лицензия күчермәсе (әлеге эшләр федераль вәкаләтле органнан үткәрелгәндә) | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |

Искәрмә. Техник мөмкинлек булганда, җир кишәрлеге урнашу схемасын электрон документ рәвешендә әзерләү, пространство белешмәләренең илкүләм системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын яисә башка технологик һәм программа чараларын кулланып, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә мәнфәгатьләре булган зат тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группадагы документлар саны |
|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр (аларны кире кайтару) | | |
| 1. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән |
| 2. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау |
| 3. | 1А-4А;<br>1Б-4Б | гариза формасында мәҗбүри кырларны, шул исәптән Республика порталында гаризаның интерактив формасында, ЕИС «Имущество»да дөрес тутырмау (дөрес булмаган, тулы булмаган, яисә дөрес тутырылмаган) |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | | |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| Җир кишәрлеген куллануга рөхсәт алганда: | | |
| 1. | 1А-4А | гариза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 1244 карары белән расланган Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирү тәртибенең 3, 4 пунктлары белән билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән |
| 2. | 1А-4А | гаризада җирләрне яки җир кишәрлеген яки урнаштырыласы объектларны куллануның күрсәтелгән максатлары РФ ҖКның $39^{34}$ статьясының 1 пунктына туры килми |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | 1А-4А | куллану өчен рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге физик яки юридик затка бирелгән |
| объектларны урнаштырырга рөхсәт алганда: | | |
| 1. | 1Б-4Б | гариза ТР МКның № 416 карары белән расланган төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру Тәртибе һәм шартларының 8 һәм 9 пунктлары белән билгеләнгән таләпләрен бозып тапшырылган |
| 2. | 1Б-4Б | гаризада күрсәтелгән күздә тотылган объектларның төрләре РФ ҖКның $39^{36}$ статьясының 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган объектлар төрләре исемлегенә керми |
| 3. | 1Б-4Б | Министрлыкка объектлар урнаштыру өчен планлаштырылган җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле милек хокукларын гамәлгә ашыру хокукы бирелмәгән, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләре йөкләнмәгән |
| 4. | 1Б-4Б | планлаштырылган җир кишәрлеге гражданнарга яки юридик затларга бирелгән |
| 5. | 1Б-4Б | планлаштырылган җир кишәрлегендә объектлар урнаштыру аны куллану рөхсәт ителгән төрдә кулланып булмауга китерә |
| 6. | 1Б-4Б | җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир Кодексының $39^{11}$ статьясының 19 пункты нигезендә үткәрелүе хәбәр ителгән аукцион предметы булып тора |
| 7. | 1Б-4Б | җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле РФ ҖКның $39^{18}$ статьясы 1 пунктының 1 подпунктына туры китереп, җир кишәрлеген хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык белән шөгыльләнү өчен бирү турында белдерү бастырылган |
| 8. | 1Б-4Б | объектлар урнаштыру өчен планлаштырылган урын “Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә генә урнаштырып була торган объектларның төрләре исемлеген раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге № 1300 карары белән расланган Дәүләти яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир |

| | | |
|---|---|---|
| | | кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә гына урнаштырып була торган объектларның төрләре исемлегенең 25 пунктында күрсәтелгәннәр арасында, велосипедларны, индивидуаль милек чараларын куюны һәм (яисә) саклауны (булуны) оештыру өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру схемасында каралмаган мондый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә мобильлек, төрле спорт инвентаре, төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру тәртибенең һәм шартларының 3 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган җир кишәрлекләрен бирмичә һәм ТР МК 416 номерлы карары белән расланган сервитутлар, гавами сервитутлар билгеләмичә генә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урнаштыру өчен рөхсәт таләп ителми |

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
_______________

___________________________________________
(физик затлар өчен - фамилия, исем, әтисенең исеме (соңгысы булса), яшәү урыны, шәхесен раслаган документ реквизитлары, ИНН)

_____________________________________________
(юридик затлар өчен - атамасы, урнашкан урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛда дәүләт теркәве турында белешмә, ОГРН, ИНН)

_____________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү турында

ГАРИЗА

Татарстан Республикасы милке булган __________________кадастр номерлы җир кишәрлеген _____________________
(җир кишәрлеген тулысынча яки җир кишәрлегенең кисәген куллану планлаштырылганда)
кадастр кварталында урнашкан җирләр, номеры ________________
____________________________________________________________________________,
(җирләрне куллану планлаштырылганда),
җир кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирүегезне сорыйм _____________________________________________________________.
(объект төре)

______________________________________________________________________.

Объектларны урнаштыру срогы_____________________________.

Россия Федерациясе законнарына туры китереп объектларны урнаштырганда

оборона һәм иминлекне тәэмин итү өчен торак пунктлар җирләре составыннан бирелгән җирләр яки җир кишәрлеге өлешләрендә, промышленность, энергетика, транспорт, элемтә, радио, телевидение, информатика җирләрендә, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләрендә, оборона, иминлек һәм башка махсус билгеләнештәге җирләрдә (Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясының 2 кисәгендәге 3 пунктында күрсәтелгән җирләр искәрмә булып тора) җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан агачларны, куакларны кисү

___________________________________

(таләп ителә /таләп ителми)

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә ______________________________________________________;

(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземпляры рәвешендә кәгазьдә; Республика порталында, ЕИС «Имущество»га шәхси кабинетка);

- Министрлыкка бирергә _____________________

_________________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземпляры рәвешендә кәгазьдә)

*Шушы мәгълүмат белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм тапшырылучы затка кагылышлы, шулай ук мин түбәндә керткән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның скан-күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшыру вакытына әлеге документлар дөрес һәм дөрес белешмәләр үз эченә ала.*

Гариза бирүче(ләр)нең, ____ №______________________ ышанычнамә буенча вәкил(ләр)нең имзасы

_________________________________________/______________________/

(гариза бирүченең, вәкиленең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булса), имза)

М.П. (мөһер булса)

Гариза кабул ителде: "___"__________20__ел _______________ /________________________________/

(/документларны кабул иткән белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Гаризага кушымта

Гаризага теркәлгән документларның исемлеге

| Документның атамасы | Битләр саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)

______________________________________

______________________________________

(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы Җыр һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече

________________________________ ____________________________

(фамилия, инициаллар) (имза)

Барлык документы 1 данә тапшырыла

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

Киңәш ителгән форма

Дәүләт яки муниципаль милкендә булган җирләрне, җир кишәрлеген яки җир кишәрлегенең кисәген куллануга
РӨХСӘТ[1]

№ ______________ Бирелү датасы _______________

_____________________________________________________________________________
(рөхсәт бирүне башкаручы вәкаләтле орган атамасы)

_____________________________________________________________________
(гариза бирүченең атамасы, телефоны, электрон почта адресы)

җир кишәрлеген (Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлеге кисәген, җирләрне) ________________________________________________ кулланырга рөхсәт итә.
(җир кишәрлеген куллану максаты)

Урнашкан урыны ______________________________________________________________
(объектны урнаштыру урыны адресы)

Җир кишәрлегенең кадастр номеры _________________________________________

Рөхсәт бирелгән срок _____________________________________________________

________________________________________________________________________________

Җир кишәрлеге чикләрендә, җир кишәрлегенең бер өлешен яисә торак пунктлар җирләре составындагы җирләрне, махсус сакланылучы территорияләр һәм объектлар җирләрен (махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләреннән тыш), сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләрен, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләрен, оборона, иминлек җирләрен һәм башка махсус билгеләнештәге җирләрдә (Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән җирләрдән тыш) урнашкан агачларны, куакларны кисүгә рөхсәт бирелүне килештерү, кисүне тыю һәм (яисә) кисүне чикләү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән очраклар чыгарылма булып тора (мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1244 номерлы карары белән расланган Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү кагыйдәләренең 3 пунктындагы «3» подпунктында күрсәтелгән мәгълүматны тапшырган очракта)

_____________________________________________________________________________

(җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән файдалану мондый җирләр яисә җир кишәрлекләре чикләрендә туфракның уңдырышлы катламын бозуга яисә юкка чыгаруга китергән очракта, рөхсәт алган затларның Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{35}$ статьясында каралган таләпләрне үтәү бурычы күрсәтелә)

________________________________________________________________________________

физик яисә юридик затка җир кишәрлеге бирелгән көннән рөхсәтнең вакытыннан алда туктатылуы турында белешмәләр һәм вәкаләтле орган тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә мондый затларга җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамә җибәрү сроклары)

Җир кишәрлеген кулланының өстәмә шартлары ________________________________________________________________________________

_________________________
(вазыйфа, фамилия, инициаллар)

[1] Территориянең кадастр планында файдалану күздә тотыла торган җирләрнең яисә җир кишәрлегенең бер өлешенең чикләре схемасы, территория чикләренең характерлы нокталарының координаталарын күрсәтеп, рөхсәт итүнең аерылгысыз өлеше булып тора

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир
кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм
сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча
кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Объект урнаштыруга
РӨХСӘТ[1]

№ __________________ Бирелү датасы ________________

_______________________________________________________________________
(объект урнаштыруга рөхсәт бирүне гамәлгә куючы вәкаләтле орган атамасы)
Татарстан Рекспубликасы милкендә булган җирләрдә
объект урнаштырырга ______________________________________________ рөхсәт бирә
(гариза бирүченең атамасы, телефоны, электрон почта адресы)

__________________________________________________________________________
объект атамасы)
Урнашкан урыны ___________________________________________________________
объектны урнаштыру урынының адресы яисә объектларны урнаштыруга рөхсәтне урнаштыру рөхсәт ителә торган объектлар һәм урнаштыру рөхсәт ителә торган урын белән чагыштырырга мөмкинлек бирә торган белешмәләр

_____________________________________________________________________________
(объектларны урнаштырган өчен түләү күләме, ешлыгы һәм вакытлары - җир кишәрлегеннән объектларның күздә тотылган төрен урнаштыру максатларында файдалану түләүле гамәлгә ашырылган очракта)

Рөхсәт ителгән срок _______________________

Җир кишәрлеге чикләрендә, җир кишәрлегенең бер өлешен яисә торак пунктлар җирләре составындагы җирләрне, махсус саклانылучы территорияләр һәм объектлар җирләрен (махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләреннән тыш), сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләрен, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләрен, оборона, иминлек җирләрен һәм башка махсус билгеләнештәге җирләрдә (Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән җирләрдән тыш) урнашкан агачларны, куакларны кисүгә рөхсәт бирелүне килештерү, кисүне тыю һәм (яисә) кисүне чикләү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән очраклар чыгарылма булып тора (мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1244 номерлы карары белән расланган Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү кагыйдәләренең 3 пунктындагы «3» подпунктында күрсәтелгән мәгълүматны тапшырган очракта)

Җир кишәрлеге, җир кишәрлеге кисәгендә яисә җирләр чикләрендә урнашкан агачларны, куакларны кисүне килештерү ____________________________

Объектны урнаштыруның өстәмә шартлары:

_____________________________________________________________________________

(җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән файдалану мондый җирләр яисә җир кишәрлекләре чикләрендә туфракның уңдырышлы катламын бозуга яисә юкка чыгаруга китергән очракта, рөхсәт алган затларның Россия Федерациясе Җир кодексының 39[35] статьясында каралган таләпләрне үтәү бурычы күрсәтелә)

_______________________________________________________________________________

(объектларны урнаштыруга рөхсәт алган зат тарафыннан җирләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона чигенең урнашу урыны тасвирламасын Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләү кирәк булган очракта тапшыруның якынча вакыты күрсәтелә)

________________________________________

(вазыйфа, фамилия, инициаллар)

[1]Объектлар урнаштыру планлаштырыла торган территориянең кадастр планындагы җирләр чикләренең яисә җир кишәрлегенең бер өлешенең схемасы, территория чикләренең характерлы нокталарының координаталарын күрсәтеп, рөхсәт итүнең аерылгысыз өлеше булып тора

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарның киңәш ителгән формасы

Җитәкчегә

_______________________________________
(юридик зат атамасы)

__________________________________
Физик затның фамилиясе, инициаллары)

________________________________ № ________белән теркәлгән гариза буенча түбәндәге нигезләрдән чыгып дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:____________________.

Баш тарту сәбәпләренә ачыклык кертү: _______________________________________________.

_____________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүчегә баш тарту сәбәпләре турында хәбәр ителә, аларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы баш тартуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән, аларга туры килмәве дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп)

Өстәмә мәгълүмат бирәбез: _________________________________________.

(хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук булган очракта башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә)

Сез күрсәтелгән кимчелекләрне төзәткәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итә аласыз.

Әлеге баш тартуны судка кадәр Министрлыкка шикаять итәргә мөмкин, судлашу тәртибендә дә шикаять итәргә була.

__________________________________________
(вазыйфа, фамилия, инициаллар)